ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КҮҢЕЛ БИЗӘКЛӘРЕ

**Розалина ШАҺИЕВА**

# СЫНЛЫ СӘНГАТЬ ОСТАСЫ ҺӘМ ШАГЫЙРЬ ХӘМИТ ЛАТЫЙФ



Бал мичкәләре

Ата-бабаларның онытылмас мәңгелек образы, татар җыры, шигърият, бөек милли орнамент тирәлегендә туган нәкышь гамәли сәнгать... Графика остасы Хәмит Латыйфның иҗаты — әйтерсең, тарих төбеннән, җир катламнарыннан үсеп чыккан мул тармаклы яшәү агачы, шәҗәрә. Аның тотрыклы хуш ис сеңдерелгән тамырлары — халкыбызның меңъеллык фольклоры, мифологиясе. Тетрәндергеч моңлы авазлары — аңарда гасырлар буена формалашкан тәвәккәл калып-архетиплар... Җилфердәп торган тармаклы, яфраклы өлеше исә бүгенге мәдәният, сәнгать шаукымнарын, гүзәллек идеалларын, эстетиканы чагылдыра. Киртләч-киртләч, каурый-каурый сызмалардан гыйбарәт «Атлы җайдак», «Ару кыз», «Батыр», «Моңлы Ана», «Шәһри Болгар», «Казан», «Тулпар», «Сак-Сок», «Йосыф вә Зөләйха», «Су анасы», «Сөембикә», «Шүрәле», «Изге елан Шахмара» кебек самими образлар — барысы да татарның мәңгелек күңел бизәкләре, аның яшәү ысулын, өметләрен, мәдәни этапларын гәүдәләндергән рухи пантеон... Коры академизм, канатсыз реализм алымнарыннан азат булган бу иҗатның гамәли асылы — рәссамның үзенә генә мәгълүм булган серле юллар, алымнар аша алып барылган өч төрле сәнгать алымына нигезләнә. Болар — керамика, агач сырлау, кәгазь яки җитен тукымага майлы буяу белән рәсем төшерү осталыгын сеңдергән гаҗәеп импровизация... Әлбәттә, монда тагын бер компонент — иҗаткәргә ярдәм итү өчен «күктән төшерелгән» магия-тылсым ярылып ята...



Тәңге җыр

Рәссамның Җиргә таянган, авыл, игенче тормышының күркәм якларын, бәйрәмнәрен мәдхияләгән, тере булмаган әйберләрне җанландыруга, декоратив бизәкләүгә корылган экологик яктан бай, оригиналь сәнгате (аның «үз теле» — әрем-яфраклары, абагалары, кош канатлары, яраткан үсемлекләре бар), әйтерсең, дөньяның бөтен могҗизасын, матурлыгын, төс-ритм үзгәлекләрен абстракт бер челтәр, сызымнар зеңгелдәвенә әйләндергән... Геометрия патшалыгы образларны ярлыландырмый, кабул итү хисен катлауландыра, үтә күренмәле затлы келәм «тукып бирә»... Менә шушы абстракт фикерләү, гомумиләштерүгә омтылу Хәмит Латыйфны 90нчы еллар башында Уфада формалашкан «Чыңгызхан» исемле татар авангардистлары төркеменә алып килә. Бу чорда ул Уфа, Казан, Оренбург, Мәскәү сәнгать казаннарында шактый гына «кайнап», «Чыңгызхан»ның мәгърур күргәзмәләрендә агач остасы, керамист сыйфатында катнаша, Чыңгыз хан портретын, куркыныч мифологик җанварлар, канатлы елан-аждаһа образларын милли калыпларга салып сынландыра.

Хәмит, 1949 елда Пермь өлкәсендә туып, 1974 елны Уфа сәнгать училищесын тәмамлаган, Чаллы, Туймазы шәһәрләрендә балалар бакчасы, кафеларны бизәп, фарфор-фаянс, сувенирлар өлкәсендә шактый эш күрсәткән була инде.

Ходайдан иңгән яшәеш, балкыш-нурларны, тылсым-ырымнарны беркатлы формулаларга әйләндерү рәссамны канәгатьләндерми. Тарихи гүзәл мизгелләрне сурәтләргә ашкынып, ул Туймазысына кайта. Ниһаять, 1996 елны, бер йөк эш төяп, «Казан» милли-мәдәни үзәгендә оештырылган шәхси күргәзмәсенә килә. Анда куелган әсәрләр тезмәсе — ялкынлы «Печән чабучылар»ы, «Егетләр», «Авыл киленнәре», малай-шалай, өем-өем печән көлтәләре арасындагы сихерле ай-йолдызлар, «Шүрәле», «Су анасы» — болар барысы да сәнгатебездә шытып чыккан милли романтизм чалымнарын тәшкил итә. Франция фовистларына тартым, Русиянең «Бубновый валет» җәмгыяте рәссамнарының иҗади идеяләре, 90нчы елгы татар авангарды җимешләре белән нурланган садә иҗат алга, меңъеллыкларга таба киләчәккә, туачак буыннарга йөз тота... Хәмит Латыйфның иҗади концепциясе, стиле, төп иҗат стратегиясе бүген шактый кулланышка кереп киткән этнофутуризм дигән сәнгать төшенчәсенә тәңгәл килә. Ниндидер микъдарда билгесезлеккә, моңлы космик киңлекләргә юлланган бу сәнгатьтә, позитив эчтәлек белән беррәттән, фаҗигале авазлар да, аңлашылмаган фантом — юлдашлар, гыйфритләр, шомлы-хәвефле астар — яшерен назым, ягъни шигърият бар.

90нчы еллар ахырыннан алып 2002 елларга кадәр ул «Туран» фондында эшли, Казанның 1000 еллыгына багышланган милли сувенир иҗат итү стихиясенә кереп китә. Бу — сырлап бизәлгән сандык-тартмалар, агач панно, гүзәл, милли аһәңле савыт-саба, йорт җиһазы — көзге, чиләк-гөбе, поднос, балчык касә, кувшин, вазалар, уенчыклар, милли агач курчаклар тудыру чоры... Борынгы Болгар көзгеләренә охшаш түгәрәк бизәкле яссылыкларга өртелгән миниатюралар... Һаман шул ук күңелне җылытып җибәрерлек таныш милли персонажлар... Агач астына сыенып, курай уйнап утырган түбәтәйле яшь егетләр; очлы борынлы, таҗ кигән, тамашачыга кукыраеп «язмыш күзе» белән карап торган мәгърур кошлар, көянтәле кызлар һәм экзотик үсемлек арасында пошкырып биеп йөргән назлы атлар!.. Боларда да, гүя төсле пастельләрдә, нәкыштә безне тоткын иткән — ата-баба авазы кебек йөрәкне ярып кабатланып, галәм киңлекләреннән төшкән хәбәр — нурланыш, рәсем, бизәк, йолдыз атылу, серле күзәнәк яшеренеп ята.



Сак белән Сок

Әйе, Хәмит чын мәгънәсендә халыкчан рәссам, аның иҗат кыйбласы — миф, гүзәл ырымнар, халык тудырган гали образлар, табигать гүзәллеге, рәссам ихтыяры белән җанландырылган бизәк вә чәчәк, орнамент.

Табышлары — милли нәфислекне, хисләрне тою, шуны нәкыш, рәсем, һәйкәлчелек ысуллары белән сынландырып бирә белү, тансык сәнгати матурлык тудыру. Иҗатының үзәге — милли моң. Шул һәвәслек аны шагыйрьлеккә, формаль булмаган поэзия дәрьясына китерде.

Нәфис сәнгать тарихында мәшһүр профессионалларның язма мирас калдырулары, каләм әһелләренә тиңләшерлек маһирлары атлаган саен очрамый.

Татар җирендә Урманчедан кала икенчеләрдән «җан сурәтен сүз сәнгате белән тоташтырган», Идел-Урал моңнарын бербөтен итеп өлгеләргә салган Х.Латыйф — бер күңел, бер олуг сәнгати җан. Заман аның төрле кылларында, клавишаларында уйный, яңа авазлар, өметләр тудыра, киләчәккә, үлемсезлеккә өнди. Иҗаткәрнең күңеле тулы яңа аһәң, шигъри моң, җем-җем йолдыз.

Түбәндә сезнең игътибарыгызга аның кайбер шигырьләрен тәкъдим итәбез.

**МОҢСУЛЫК**

Нигә шулай йөзең моңсу, диеп
Сорый миннән күргән танышлар;
Бәлки, шулай моңсу итәдер, дим,
Галәмнәрдә иңгән сагышлар.

**ИСКЕ КӨЙ**

Тыңладым мин, хәтта еладым мин,
Нинди моң ул, диеп, татарда, –
«Карурман»ның уртасында калам,
Үткәннәргә борылып кайтам да.

**БУРЫЧ**

Миһербансыз кара көннәрдә дә
Иманыңны саклап каласы;
Җан туңса да, чәчләр агарса да,
Хак эш өчен әле янасы.

**30 АВГУСТ КИЧЕ**

Офыкларда яна кызыл шәфыкъ –
Үткәннәрнең төсеме ул әллә?
Күз алдына килде дөрләп янган
Казан,
Тетрәп киттем, күккә карап
шушы мәлдә.

**АК БҮРЕМЕ ӘЛЛӘ АВАЗ САЛДЫ...**

Рух чакыруы булып тарихлардан
Ак бүреме әллә аваз салды;
Бер йолдызның канатлары янып,
Кара күктән җанга ак нур тамды.

**БАЛАЧАК**

Сарай башы, койма башы аша
Үтеп китте безнең балачак.



Илһамлану

Өнсез йөргән ачыгавызларны
Бу язмышлар әле табачак.

**БӘХЕТ**

Кемнәр килеп аны аралар,
Сыза-сыза әрни яралар.
Ахмак илдә ахмак бәхетле,
Акыллысы күрер җәфалар.

**БАЛАЧАК ИСТӘЛЕГЕ**

Авыл капкасыннан атлар узды,
Атлар белән китте абыйлар.
Читән башларыннан карап калды
Кулын болгап үксез сабыйлар.

**БИТАРАФЛЫК**

Әнә бериш алар,
Исе китми,
Сине тыңлап озак утырмас.
Туган телем диеп ана телен,
Китаплардан эзләп укымас.